# “Ислам” сүзенең һәм аның нигезләренең аңлатмасы

Шәех Гәбдүлгәзиз ибн Гәбдуллаһ ибн Бәз

(Гарәпчәдән тәрҗемә)

## ТӘРҖЕМӘЧЕДӘН КЕРЕШ СҮЗ.

**БисмиЛләһи-р-Рахмәни-р-Рахиим.**

(Рәхмәт иясе һәм Рәхимле булган Аллаһ исеме белән!)

Барча мактау Аллаһ Тәгаләгә тиешле! Без Аңа шөкер кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Нәфсебезнең начарлыгыннан, бозык гамәлләребездән Аллаһ Тәгаләдә сыену эзлибез!
Кемне Аллаһ туры юлга күндерсә, аны беркем дә адаштырмас, ә кемне адаштырса – беркем дә туры юлга күндерә алмас. Шәһадәт бирәмен – Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы һичбер иләһ юк, ул берүзе, тиңдәшсез һәм шәһадәт бирәмен – Мөхәммәд Аллаһның колы һәм илчесе!

Кадерле укучы! Ислам дине буенча яшәү һәм аның төрле гыйбадәтләрен үтәү, кешегә Кыямәт көнендә әҗер-саваплы булу һәм Җәннәткә ирешүгә өстәмә булып, бу дөньяда да аерым шәхеснең тормышын һәм җәмгыятьнең халәтен бөтен яктан төзәтә һәм яхшырта. Әлеге китапчыкта, кыскача гына, Ислам диненең асылы һәм аның нигезләре аңлатылып узыла. Китапчык Коръән аятьләре һәм пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ хәдисләре белән дәлилләнеп, гади тел белән язылган. Аның авторы хәзерге заманның мәшһүр галиме, имам, мөфти Шәех Гәбдүлгәзиз ибн Гәбдуллаһ ибн Бәз (Аллаһ аңа рәхимле булсын). Бу китапчык шәех ибн Бәзның “Фәтваләр һәм төрле мәкаләләр җыелмасы”нда урын алган. Әлеге галим һиҗри исәп буенча 1330-нчы елда (миләди буенча 1912-нче ел) туган. Балигълык яшенә җиткәнче Коръәнне яттан өйрәнеп чыккан. Унтугыз яшенә җиткәч, шәех, күз авыруы сәбәпле, тулысы белән сукырая. Әмма бу аңа гыйлем алырга, шул гыйлемгә нигезләнеп Ислам динен таратуга бернинди дә киртә тудырмый. Шәех үзенең гомерен шул юлда – гыйлем алып, гамәл-гыйбадәттә булып, дәресләр биреп, төрле дини вазыйфалар башкарып, мөселманнарның борчу-мәшәкатьләрен чишеп һ.б төрле хәерле эшләрдә үткәрә, үзеннән соң бик күп укучылар, төрле китаплар һәм мәкаләләр, аудио һәм видео форматта язылган дәресләр калдыра. Шәех ибн Бәз һиҗри исәп буенча 1420-нче елда (миләди буенча 1999-нчы ел) вафат була. Аллаһ Тәгалә аны да, безне дә гафу кылып, рәхимле булып, Үзенең Фирдәвес җәннәтләрендә урнаштырса иде, әмин!

**[Татарчага тәрҗемә, төп мәгънәсен югалтмыйча, кайбер кыскарту һәм үзгәртүләр белән бирелде. Кайсыбер терминнарның мәгънәләренә ачыклык кертү өчен тәрҗемәче тарафыннан кыска гына сылтамалар куелды һәм берничә урында хәзерге заманның билгеле галиме шәех Мөхәммәд Һишәм Таһириның шушы китапчыкны шәрех кылганда биргән аңлатмасы да урын алды].**

**БисмиЛләһи-р-Рахмәни-р-Рахиим.**

(Рәхмәт иясе һәм Рәхимле булган Аллаһ исеме белән!)

Гыйбадәткә лаеклы бердәнбер Аллаһка барча хәмед һәм ахыргы пәйгамбәр Мөхәммәдкә Аллаһның мактавы һәм сәламе булсын.

Һәм аннан соң:

Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтте: **"Бүген динегезне төзеп бетереп тулы кылдым һәм сезгә нигъмәтләремне Ислам дине белән биреп бетердем, һәм риза булып Ислам динен сезгә ихтыяр кылдым".** ("Әль-Мәидә" сүрәсе, 3-нче аять). Шулай ук әйтте: **"Шиксез, Аллаһ каршында Ислам дине генә дин".** ("Әлү-Гыймран" сүрәсе, 19-нче аять). Һәм, шулай ук, Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Берәү Ислам диненән башка дингә иярсә, аның дине вә гамәле һич кабул булмый, ул ахирәттә хәсрәтләнүче вә һәлак булучыдыр".** ("Әлү-Гыймран" сүрәсе, 85-нче аять).

Ислам ул – бериләһлек[1] аша Аллаһка буйсынып, Аның әмерләренә күндәм булу, ширектән[2] һәм ширек кылучылардан ерак тору. Мөхәммәд ﷺ [3] пәйгамбәр булып кешеләрне иманга чакыра башлаганчы, ширек - гарәпләрнең дине иде. Имам әль-Бохари үзенең хәдисләр җыентыгында Әбу Раҗә әль-Гәтаридидән китерә: *"Җаһилият[4] заманында без ташларга гыйбадәт кылдык. Әгәр дә бер таштан яхшырак булган икенче таш тапсак – иске ташны калдырып яңасына гыйбадәт кыла башлый идек. Ә инде таш таба алмасак, комнан калкулык ясап, сарык алып килеп, шул калкулыкка сөтен савып, аның тирәли тәваф[5] кыла башлый идек".* Ә инде гомумән алганда, Мөхәммәд ﷺ пәйгамбәр булып килгәнче, күпчелек өммәтләрнең халәтен безгә Коръән ачык аңлата: **"Алар Аллаһтан башка зарар үә файда китерә алмый торган затларга гыйбадәт кылалар һәм әйтәләр: "Болар Аллаһ каршында безнең шәфәгатьчеләребез".** ("Йуныс" сүрәсе, 18-нче аять), шулай ук: **"Аллаһтан башка иләһләрне яклаучы итеп тоткан мөшрикләр: "Без аларга гыйбадәт кылмыйбыз, мәгәр безне Аллаһка якынайтсыннар өчен генә гыйбадәт кылабыз".** ("Әз-Зүмәр" сүрәсе, 3-нче аять), шулай ук Аллаһның сүзләре: **"Без шәйтаннарны ышанмаучыларга дус кылдык. Кайчан бозык эшне кылсалар:**

---

1 Гарәпчә "әт-тәүхид" – бериләһлек – Аллаһны гына бердәнбер хак иләһ дип танып, барча гыйбадәтләрне бер Аңа гына кылу. Әт-тәүхид – Ислам диненең нигезе һәм асылы. Иләһләр – кешеләр тарафыннан гыйбадәт кылына торган төрле затлар.

2 Ширек (гарәп термины) – күпиләһлек – Аллаһ белән беррәттән төрле затларга гыйбадәт кылу. Аллаһ Тәгалә каршында иң олы гөнаһ булып санала. Аллаһ әйтте: **"Чынлыкта Аллаһ үзенә ширек кылуны гафу итмәс, а калган гөнаһларны кемгә тели, шуңа гафу итәр".** ("Ән-Нисә" сүрәсе, 48, 116 нчы аятьләр).

3 ﷺ - аңа Аллаһның мактавы һәм сәламе булсын.

4 Җаһилият (гарәп термины) – Ислам дине килгәнче вакыт.

5 Тәваф (гарәп термины) – гыйбадәт нияте белән нәрсәдер тирәли әйләнү. Ислам динендә бары тик Мәккәдә урнашкан Кәгьбәтуллаһ тирәли генә тәваф кылырга рөхсәт ителә.

**“Ата-бабаларыбызның бу эшне эшләгәннәрен күрдек һәм Аллаһ әмер кылды бу эшне кылырга”, - диләр, әйт [йә, Мөхәммәд]: “Чынлыкта Аллаһ бозык эшне әмер кылмады, белмәгән килеш Аллаһка яла ягасызмы?!” - дип”.** (“Әль-Әграф” сүрәсе, 27-28 нче аятьләр), һәм Аллаһның сүзләренә кадәр: **“Алар Аллаһтан башка шәйтаннарны дус итеп алдылар, шулай булса да алар: “Без туры юлга күнелгән кешеләр”, - дип исәпләделәр”.** (“Әль-Әграф” сүрәсе, 30 нчы аять), шулай ук Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Мөшрикләр, Аллаһ үстергән игеннәрдән, дүрт аяклы хайваннардан Аллаһка өлеш кылдылар, үз белдекләре белән бу иген вә бу хайван Аллаһ өлеше булыр, вә бу иген һәм бу хайван сыннарыбызның өлеше диделәр, сыннары өчен билгеләнгән игеннәре вә хайваннары Аллаһка ирешмәс, әммә Аллаһ өлеше дип билгеләнгән иген вә хайваннары сыннарына ирешер, ни ямандыр аларның хөкемнәре”.** (“Әль-Әнгәм” сүрәсе, 136 нчы аять). Коръәндә мондый мәгънәдәге аятьләр күп килә.

Һәм инде пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләре, аның тормыш юлына багышланган китаплар һәм, шулай ук, тарих китапларына килгәндә, алардан без Мөхәммәд ﷺ пәйгамбәр булып килгәнче, әүвәлге кавемнәрнең халәтен күрәбез – бу халыклар төрледән-төрле иләһләргә гыйбадәт кыла иделәр. Алар арасында сыннарга һәм потларга, кәбер әһелләренә, кояшка, айга, йолдызларга һ.б. әйберләргә табынучылар бар иде.[6] Һәм Аллаһның илчесе Мөхәммәд ﷺ шушы халыкларны Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырды, аларның һәм ата-бабаларының гыйбадәт кыла торган иләһләре ялган иләһләр икәнен аңлатты. Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтте: **“Әйт: Йә кешеләр! Чынлыкта мин барчагызга – бөтен дөнья кешеләренә Аллаһтан җибәрелгән рәсүлмен. Җир вә күкләр байлыгы Аллаһ милке, Аллаһтан башка хак иләһ юк, Ул тергезә вә үтерә, Аллаһка һәм укый-яза белмәгән рәсүленә ышаныгыз! Ул – рәсүл, Аллаһка вә Аның сүзләренә ышана, аңа иярегез, шаять туры юлга күнәрсез!”.** (“Әль-Әграф” сүрәсе, 158 нче аять). Һәм әйтте: **“Ошбу китапны сиңа иңдердек, кешеләрне караңгылыктан чыгарып, хак дин яктылыгына кертмәклегең өчен Раббыңның теләге белән Бөек вә мактаулы Аллаһ юлына”.** (“Ибраһим” сүрәсе, 1 нче аять). Шулай ук: **“Йә пәйгамбәр, Без сине кешеләргә шаһит итеп, сиңа ияреп Коръән белән гамәл кылучыларны яхшы хәбәр белән сөендерүче, һәм Коръән белән гамәл кылмаучыларны җәһәннәм белән куркытучы итеп җибәрдек. Сине Аллаһның рөхсәте һәм әмере буенча кешеләрне Аллаһка иманга өндәүче, туры юлны яктыртучы иттек”.** (“Әль-Әхзәб” сүрәсе,

---

6 Хәзерге заманда кешеләр әлеге санап үтелгән әйберләр өстенә әле тагын бик күп затларга гыйбадәт кылалар, хәтта алар арасында җәнлек-хайваннарга, төрле тимер һәм таш кисәкләренә һ.б. нәрсәләргә табынучылар бар, шушы әйберләр белән үзләренең теләк-омтылышларын бәйлиләр, безне төрле начарлыклардан саклый дип уйлыйлар. Хәтта кешеләр арасында “галим, профессор” исемен йөртүче кеше дә тормышында нинди дер җансыз әйберләргә гыйбадәт кылучылар динендә булырга мөмкин. Болар барысы да тәүхид фәненең, дөрес Ислам тәгълиматенең мөһимлеген күрсәтә. (Шәех Мөхәммәд Һишәм Таһири аңлатмасы).

45-46 нчы аятьләр). Шулай ук: **“Ә бит аларга Аллаһка ихлас рәвештә хәниф булып гыйбадәт кылырга, намаз үтәргә һәм зәкәт бирергә генә әмер кылынган иде”.** (“Әль-Бәййинә” сүрәсе, 5 нче аять). Шулай ук: **“Йә кешеләр! Сезне һәм сездән элек булган кешеләрне халык кылучы Аллаһка гыйбадәт кылыгыз! Бәлки Аллаһтан куркучы, тәкъвә булырсыз”.** (“Әль-Бакъара” сүрәсе, 21 нче аять). Шулай ук: **“Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылырга”.** (“Әль-Исра” сүрәсе, 23 нче аять). Коръәндә мондый мәгънәдәге аятьләр күп килә.

Аллаһ Тәгалә Коръәндә бик күп аятьләрдә әүвәлге мөшрикләрнең хәлен аңлатты: алар Аллаһка ширек һәм көферлек кылулары белән беррәттән, Аллаһны – аларны бар кылучы, ризыкландыручы икәнен таныдылар, ләкин Аллаһтан башка әйберләргә гыйбадәт кылуларының сәбәбе – шуларны Аллаһ белән үзләре арасында арадашчы, шәфәгатьче итеп алулары иде. Алдан китерелгән аятьтә әйтелгәнчә: **“Алар Аллаһыдан башка зарар вә файда китерә алмый торган затларга гыйбадәт кылалар һәм әйтәләр: “Болар Аллаһ хозурында безнең шәфәгатьчеләребез”.** (“Йуныс” сүрәсе, 18-нче аять). Һәм шушы әйтелгәнне раслаучы башка аятьләрне дә китерергә була: **“Сора алардан: “Җир вә күкләрдән кем сезне ризыкландыра? Яки хуҗа булып сезгә күз вә колакларны кем бирә? Кем үлектән терекне һәм теректән үлекне чыгара? Бөтен эшләр белән кем идарә итә? Алар әйтер: “Аллаһ”. Әйт: “Шулай булгач Аллаһтан курыкмыйсызмы?”.** (“Йуныс” сүрәсе, 31-нче аять). Һәм шулай ук: **“Әгәр син алардан сезне кем бар итте дип сорасаң, алар, әлбәттә, Аллаһ бар итте диячәкләр”.** (“Әз-Зухруф” сүрәсе, 87-нче аять). Һәм шундый мәгънәдә бик күп ачык аятьләр бар.[7]

Мөхәммәд ﷺ Аллаһның ахыргы пәйгамбәре булып, гарәп халыклары өчен генә түгел, ә Җир йөзендә барча халыклар өчен дә Ислам дине белән килде. Кешелек җәмгыяте бу вакытта көферлек һәм ширек караңгылыгыннан иман һәм тәүхид яктылыгына чыгаручыга бик мохтаҗ иде.

Һәм бу бөек дин – Ислам дине – биш нигезгә төзелгән, бу нигезләр Ислам диненең әркәннәре яки Ислам диненең биш баганасы дип йөртелә. Имам әл-Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгында килә: ‘Габдуллаһ бине Гомәр (Аллаһ алардан разый булсын) сөйләгән: *«Мин Аллаһ Илчесенең болай дигәнен ишеттем: «**Ислам биш тәрәккә нигезләнә: «Аллаһтан башка хак иләһ юк, Мөхәммәд – Аның Илчесе» дип шәһәдәт бирү, намаз үтәү, зәкят бирү, Хаҗ кылу, Рамазан аенда ураза тоту”.***

---

[7] Бу мәгънәдәге Коръән аятләреннән без әүвәлге мөшрикләрнең ширек динен тотуының төп ике сәбәбен күрәбез:

- беренчесе, дәлилләргә нигезләнмичә ата-бабалар диненә ияртү;
- икенчесе, гыйбадәт кыла торган затларын Аллаһ белән үзләре арасында арадашчы, шәфәгатьче итеп алу, ягъни бу гамәл ширек түгел дип ялган ышану. (Шәех Мөхәммәд Һишәм Таһири аңлатмасы).

Ислам диненең беренче баганасы булып шәһәдәт кәлимәсе тора. Һәм бу шәһәдәт кәлимәсе – беренчесе дә һәм иң мөһиме дә. Шушы кәлимәне әйтеп кеше Ислам диненә керә, ягъни мөселман була. Әмма бу кәлимәне тел белән генә әйтү җитми, аның шартларын үтәү кирәк. Һәм шул шартларның берсе булып, Аллаһ Тәгаләгә ихлас рәвештә гыйбадәт кылып, Аны гына гыйбадәткә лаеклы, Аллаһтан башка әйберләргә гыйбадәт кылу - батыл гамәл дип тану тора.

Шулай ук, бу шәһәдәт кәлимәләре Аллаһ Тәгаләне һәм Аның расүлен ﷺ яратуны сорый. Ә инде әлеге ярату Аллаһның Берүзенә генә гыйбадәт кылуны, Аны олылауны һәм Аның расүленә ﷺ иярүне таләп итә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Йә Мөхәммәд әйт: "Әгәр Аллаһны яратсагыз - миңа иярегез, Аллаһ сезне яратыр һәм гөнаһларыгызны ярлыкар".** ("Әлү-Гыймран" сүрәсе, 31-нче аять). Шулай ук, әлеге кәлимә Аллаһ расүленең ﷺ әмерләренә буйсынуны да сорый. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Пәйгамбәр сезгә нәрсә китерсә – кабул итеп алыгыз, нәрсәдән тыйса – тыелыгыз!".** ("Әл-Хәшер" сүрәсе, 7-нче аять). Һәм сахих[8] булып торучы хәдистә Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***"Кемдә өч сыйфат бар – шул иманның татлы тәмен татыячак: [кешегә] Аллаһның һәм Аның расүле калган башкалардан иң сөеклесе булу…"*** хәдис ахырына хәтле. Һәм, шулай ук, Пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләре: **"*Берегезнең дә иманы тулы булмас, мине үзенең ата-анасыннан, баласыннан һәм башка кешеләрдән дә катырак яратканчыга хәтле".***

Ә инде Ислам диненең икенче баганысына килгәндә – бу биш вакыт намаз үтәү булып тора, үзенең мөһимлеге буенча ике шәһәдәттән соң килә. Намаз үтәү – диннең терәге, Кыямәт көнендә кешенең гамәлләреннән иң беренче соралачак әйбер. Әгәр дә кешенең намазлары яхшы булса – ул уңышка һәм бәхеткә ирешер, ә инде киресенчә булса – кеше югалтуда һәм хәсрәттә булыр. Намаз аерым чикләре билгеләнеп куелган вакытта үтәлергә тиеш, Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Дөреслектә намаз - вакыты билгеләнгән фарыз гамәл итеп йөкләтелде".** ("Ән-Нисә" сүрәсе, 103-нче аять). Аллаһ Тәгалә намазларны тиешенчә сакларга боерды: **"Ий мөэминнәр! Намазларыгызга сакчыл булыгыз, ягъни намазны күтәп алып, әүвәл вакытында укыгыз, хосусан икенде намазына игътибар бирегез, бер нәрсә дә сәбәп булмасын намазны калдырырга яки кичектерергә, һәм намаз укыганда Аллаһтан куркып, нык бирелеп укыгыз һәм намазда түбәнчелек белән торыгыз!".** ("Әл-Бәкъара" сүрәсе, 238-нче аять).

Аллаһ - намазларына җиңел караучыларга һәм вакытында укымаучыларга янады: **"Ул пәйгамбәрләрдән соң явыз кавем килде, алар намазларын кичектереп яки бөтенләй укымыйча калдырдылар, вә шәһвәткә, нәфес теләгән нәрсәләргә иярделәр, алар тиздән ахирәттә газапка очраучылардыр".** ("Мәрьям" сүрәсе, 59-нчы аять). Шулай ук: **"Ни үкенеч вә һәлакәтлек ихлассыз намаз укучыларга. Алар намазларыннан гафилләр, вакытында укымаслар һәм намазның рөкеннәрен**

---

[8] Сахих – дөреслеге расланган иң югары дәрәҗәдәге хәдис.

**хөрмәт кылмаслар, намазларының вакытыннан кичегүенә кайгырмаслар”.** (“Әл-Мәгүн” сүрәсе, 4,5-нче аятьләр).

Намаз – Ислам динен көферлек һәм ширектән аерып тора торган бер билге. Имам Мөслим үзенең “Сахих” хәдисләр җыентыгында Җәбир исемле (Аллаһ аннан разый булсын) сәхабәдән китерә: *мин пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләрен ишеттем*: ***“Кеше белән көферлек һәм ширек арасында намаз үтәмәү тора”*** (Мөслим, Иман китабы, 82-нче хәдис). Бүрайдә исемле (Аллаһ аннан разый булсын) сәхабәнең хәдисендә килә: ***“Безнең белән алар арасында килешү – намаз, кем намазны калдырды, шул көферлек кылды”*** (Имам Әхмәд һәм “Әс-Сүнән” китаплары авторлары сахих юл белән китерәләр).

Шулай ук, намазны мәчеттә җәмәгать белән үтәү тиешле[9]. Чөнки җәмәгать намазының фазыйләте бик зур. Ибн Гомәрдән (Аллаһ алардан разый булсын) риваять кылына: *пәйгамбәребез ﷺ әйткән*: ***“Җәмәгать намазы ялгыз укылган намаздан 27 дәрәҗә фазыйләтлерәк”*** (Имам Әл-Бохари һәм имам Мөслим китерәләр).

Имам әль-Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыкларында пәйгамбәребезнең ﷺ хәтта мәчеткә җәмәгать намазына килмәүчеләрнең намаз вакытында өйләренә барып, өйләренә ут төртеп яндырырга теләк белдерүе дә әйтелә. Пәйгамбәребездән ﷺ шундый хәдис тә килә: ***“Кем намазга чакыруны (азан) ишетте һәм аңа җавап бирмәде, ул кешенең гозере булмаса - намазы юктыр”*** (Имам ибн Мәҗәһ, әд-Дәракъутни, ибн Хиббән, әл-Хәким сахих юл белән китерәләр). Һәм бу хәдисләр намазны җәмәгать белән үтәүнең бөек гамәл икәнен күрсәтәләр.

Намазның камиллеге һәм Аллаһ Тәгалә тарафыннан кабул булуының шартлары булып, намазны хошугълык[10] һәм тынычлык[11] белән уку тора. Аллаһ Тәгалә әйтә: **“Чынлыкта мөэминнәр ґазабтан котылып мәңгелек сәгадәткә ирештеләр. Алар намазларын хошугъ белән укыйлар, Аллаһудан куркып, кечерәяләр”.** (“Әл-Мөэминүн” сүрәсе, 1,2-нче аятьләр). Пәйгамбәребез дә ﷺ тынычлык белән намаз укымаучы бер кешегә намазын кабаттан укырга боерды.

Намаз кешеләрне бердәмлеккә һәм кардәшлеккә өйрәтә, чөнки кешеләр намаз укыганда бер рәткә басып, бер-берсенә нык терәлеп, йөзләре белән бер якка – Кыйбла тарафына юнәләләр. Намаз, шулай ук, күңел өчен ял итү һәм ләззәт булып тора, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Минем күңел ял итүем – намаз булды”.*** Пәйгамбәребезне ﷺ күңелен төшерә яки куркуга сала торган берәр хәл булса – ул намаз укый иде, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтә: **“Аллаһудан ярдәм сорагыз – тормыш вә дин юлындагы төрле**

---

9 Ир-атлар өчен.

10 Гарәпчә “хушугъ” - Аллаһның әҗерен өмет итеп һәм газабыннан куркып, Аллаһ Тәгалә каршында түбәнчел һәм басынкы булу.

11 Гарәпчә “туməэнинә” – намазның әркәннәрендә тыныч рәвештә тиешле зекерне үтәү, мәсәлән, сәҗдә кылганда кимендә өч тапкыр “сүбхәнә рабби-әл-әгълә” дип әйтү.

**авырлыкларга сабыр итеп һәм намазларыгызны үтәү белән".** ("Әл-Бәкара" сүрәсе, 153-нче аять). Һәм Пәйгамбәребез ﷺ үзенең мөәзине[12] Биләлгә: ***"Йә, Биләл, безгә ял китер",*** ягъни "азан әйт тә, намаз укып күңелләребезгә ял алыйк" – дип әйтә торган булган.

Чөнки мөселман кеше намазга баскач, үзен юктан Бар кылучы Аллаһ Тәгалә каршында басып торганын аңлый һәм шуның белән калебенә ял, җанына һәм тәненә тынычлык, түбәнчелек һәм басынкылык ала, үзенең Яклаучысы алдында торганын белеп, күңеле ләззәтләнә.

Ислам диненең өченче баганасы булып зәкәт бирү тора. Зәкәт – җәмгыяти фарыз[13] гамәл, ягъни ислам җәмгыятендә билгеле бер күләмдәге малга ия булган кешеләр тарафыннан мохтаҗларга бирелә торган өлеш. Һәм бу гамәл, мохтаҗларның хәленә кереп, кешеләр арасында рәхим-шәфкатьлелек, ярату хисе, бер-береңә ярдәм итүне арттыра. Чөнки кешегә килгән мал-мөлкәт – Аллаһ Тәгаләдән, һәм Аллаһ Тәгалә әмер бирә шул малдан күпмедер өлешне мохтаҗларга чыгарырга, ягъни бу өлеш – мохтаҗлар хакы булып тора. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Без сезгә биргән малдан өлеш бирегез".** ("Ән-Нур" сүрәсе, 33-нче аять). Шулай ук Аллаһ Тәгалә сүзләре: **"Ий кешеләр, Аллаһка вә Аның рәсүленә иман китерегез, вә сезгә куллану өчен бирелгән малларыгыздан Аллаһ күрсәткән урыннарга садака бирегез! Сезләрдән иман китереп дин тоткан хәлдә садака бирүчеләр – аларгадыр олугъ әҗерләр".** ("Әл-Хәдид" сүрәсе, 7-нче аять). Көрьәндә бик күп аятьләрдә зәкәт намаз белән бергә искә алына. Әбү Бәкернең (Аллаһ аннан разый булсын), пәйгамбәребез ﷺ вафатыннан соң хәлифә булгач, кайбер кабиләләр зәкәт бирүдән баш тарткач, бу кабиләләр белән сугыш алып баруы да билгеле, һәм ул бу вакытта "*Аллаһ белән ант итәмен – мин намаз белән зәкәтне аерган халыклар белән сугышны дәвам итәчәкмен*" дип әйтә торган булган, һәм калган сәхабәләр аның белән килешкәннәр. Ягъни болар барысы да зәкәтнең әһәмиятен күрсәтә.

Аллаһ Тәгалә мохтаҗларга зәкәт-сәдака бирүгә саран булган кешегә янады: **"Янә бар шундый кешеләр, алтын вә көмешне җыеп асрарлар, Аллаһ юлына һич тә бирмәсләр, аларга рәнҗеткүче ґазаб булачагы белән хәбәр бир".** ("Әт-Тәүбә" сүрәсе, 34-нче аять).

Ә инде зәкәт бирүнең тәртибенә килгәндә, ягъни зәкәт бирү кемгә тиешле дигәндә, зәкәт – бер һиҗри ел эчендә аерым төр мал-мөлкәте аерым бер күләмгә җиткән кешегә фарыз-вәҗиб булып тора. Иллә-мәгәр җирдән үсеп чыккан уңыштан кала – бу очракта бер ел үтү шарт булып тормый, ягъни уңыш өлгереп җыеп алынгач, шул уңыштан өлеш бирелергә тиеш. Зәкәт кемнәргә бирелә дигәндә, Аллаһ Тәгалә зәкәт бирелергә

---
12 Мөәзин – азан әйтүче.
13 Фарыз яки вәҗиб гамәл – кем бу гамәлне үти, аңа әҗер-савап була, кем калдыра – гөнаһка керә.

тиешле кешеләрне Көрьәндә атап узды: **“Садакалар – фәкыйрьләргә, мескеннәргә, әмир тарафыннан куелган зәкят җыючыларга, вә исламга күңелләре тартылган кешеләргә, коллыктан азат итүгә, бурычын түләргә көче җитмәгән бурычлы кешеләргә, ислам дине өчен Аллаһ юлына һәм малсыз калган мөсафирләргәдер, шул күрсәтелгән урыннарга бирү Аллаһтан фарыз ителде”.** (“Әт-Тәүбә” сүрәсе, 60-нчы аять).

Ислам диненең дүртенче баганасы – Рамазан аенда ураза тоту. Моңа Аллаһның сүзләре дәлил булып тора: **“Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә ураза тоту фарыз ителде, шаять, тәкъвалы булырсыз!”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 183-нче аять).

Рамазан аенда бер ай буена ураза тотып, мөселман кеше үзенең төрле нәфес теләкләрен һәм шәһвәтләрен буйсындырырга өйрәнә, рухи яктан сәламәтләнә, шуның өстенә ураза тоту тәнгә дә сихәт бирә, ягъни бу рухи сәламәтлеккә бер өстәмә булып тора. Ураза аша мөселман үзенең мохтаҗ яшәүче кардәшенең хәленә керә, аны аңлый башлый, чөнки дөньялыкта әз генә ризыкка һәм хәтта суга да тилмереп яшәүчеләр бар, мисал өчен, Африканың кайсыбер илләрендә яшәүче мөселман кардәшләребез кебек.

Рамазан ае – айлар арасында иң яхшысы һәм дәрәҗәлесе.[14] Бу айда Аллаһ Тәгалә Көрьәнне иңдергән: **“Рамазан ае бик шәриф ай, ул айда Аллаһтан кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидәятне ачык бәян кылучы Корьән иңдерелде”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 185-нче аять). Шулай ук, бу айда мең айдан да хәерлерәк булган Кадер кичәсе бар: **“Чынлыкта Без Корьәнне иңдердек Кадер кичендә. Сиңа Кадер кичнең шәрифлеген вә аның хикмәтен нәрсә белдерде? Кадер киче, мең айдан да хәерлерәк”.** (“Әл-Кадер” сүрәсе, 1-3 нче аятьләр).

Әгәр дә, ураза тотучы кеше үзенең уразасын Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп тотса – бу кешенең алда кылган гөнаһлары гафу кылыныр. Әбу Һөрайрадан (Аллаһ аннан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: **“*Кем Рамазан аеның [көннәрен] Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп ураза белән уздырса – аның алдагы гөнаһлары кичерелер, һәм, кем Рамазан аеның [төннәрен] Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп тәравих намазларын укып уздырса – аның алдагы гөнаһлары кичерелер, һәм, кем Кадер кичәсен Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп гыйбадәт белән уздырса – аның алдагы гөнаһлары кичерелер”.*** (Имам Әл-Бохари һәм имам Мөслим китерәләр).

[14] Галимнәр арасында фикер каршылыгы юк айлар арасында Рамазан ае, атна көннәре арасында җомга көн иң дәрәҗәлесе булуында. Һәм инде, дөрес фикер буенча, иң яхшы төн – Кадер киче, иң яхшы көн – Гәрәфә көне. (Шәех Мөхәммәд Һишәм Таһири аңлатмасы).

Шуңа күрә, ураза тотучы кеше үзенең уразасында гайбәт-сүз сөйләүдән, сүз йөртүдән, ялганнан, кирәкмәгән буш сүзләрдән һәм башка төр гөнаһ гамәлләрдән үзен тыеп торырга тиеш. Рамазан аенда ураза тотканда Көръән укуны, Аллаһны зекер кылуны, сәдака бирүне арттыру, үзеңнең күпчелек вакытыңны гыйбадәткә багышлау (аеруча Рамазан аеның ахыргы ун көнендә) сөннәт булып тора.

Ислам диненең бишенче баганасы – Мәккә шәһәрендә урнашкан Әл-Хәрам мәчетенә Хаҗ кылу. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Көче җиткән кешеләргә Аллаһка гыйбадәт өчен Хаҗ кылу фарыз”.** (“Әлү-Гыймран” сүрәсе, 97-нче аять).

Хаҗ кылу гомергә бер тапкыр, шулай ук, кече Хаҗ - Гомрә дә гомергә бер тапкыр тиешле. Мөселман булган, үз акылында булган, балигълык[15] яшенә җиткән, ирекле (ягъни коллыкта булмаган), хәленнән килгән кеше өчен тиешле булып тора. Сабый бала үзенең әти-әнисе белән Хаҗ кыла икән, аның Хаҗы дөрес була, әмма балигълык яшенә җиткәч – тагын бер мәртәбә үтәргә тиеш, ягъни сабый чакта үтәгән Хаҗ белән Гомрәсе балигълык яшендә тиеш булган Хаҗ белән Гомрәне алыштырмый. Ә инде хатын-кызга килгәндә, әгәр дә аны Хаҗ сәфәренә алып чыгарлык мәхрәме[16] булмаса, бу хатын-кызга Хаҗ кылу да, Гомрә дә тиешле түгел, ягъни мәҗбүрилеге төшә. Чөнки пәйгамбәребез ﷺ хатын-кызга мәхрәмнән башка сәфәргә чыгуны тыйды. Хаҗ ул – дөньяның төрле почмакларыннан килеп, төрле милләттән, төрле телдә булган мөселманнарның бергә җыелу вакыты һәм урыны. Бу вакытта мөселманнар барысы да бер төрле кием киеп, бер җиргә җыелып, бергәләшеп, бер-берсенә ярдәм итеп, бөтенесе дә бер төрле гыйбадәт башкаралар. Ягъни, Хаҗны үтәгән вакытта, олымы, кечеме, баймы, ярлымы, ак тәнлеме, кара тәнлеме – кешеләр арасында аерма калмый, бөтенесе дә бертигез хәлдә булалар. Аллаһ Тәгалә Көръәндә әйтә: **“Ий кешеләр, Без сезләрне ир вә хатын итеп халык кылдык, вә сездән тармаклар вә кабиләләр кылдык бер-берегезне танып аерыр өчен, чынлыкта Аллаһ хозурында иң хөрмәтлегез – иң тәкъвалы булучыгыз”.** (“Әл-Хүҗүрат” сүрәсе, 13-нче аять).

Ә инде, Хаҗны гонаһлардан сакланып, ихлас рәвештә һәм һәрбер әркәннәрен тиешенчә җиренә җиткереп үтәгән кешегә[17] иң зур бүләк – Җәннәтле булу! Чөнки Имам Әл-Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыкларында Әбу Һөрайрадан

---

[15] Балигълык – кешегә карата шәригать йөкләмәләре һәм хөкемнәре мәҗбүри була башлаган вакыт, яшь. Ислам дине буенча, баланың төнге поллюцияләре башланса, яки җенес әгъзасы тирәсендә каты төкләр чыкса, яки кызларның күремнәре башланса, әгәр дә инде бу билгеләрнең берсе дә күренмәсә, әмма яше һиҗри исәп буенча 15 яшькә җитсә – балигълык яшенә җиткән булып санала.

[16] Мәхрәм – хатын-кызга туганлык сәбәпле кияүгә чыгарга ярамаган ир-атлар, алар өч төр категориягә бүленә:

- нәсел туганлыгы (хатын-кызның әтисе, бабасы, улы, абыйсы, энекәше һ.б.);
- сөт имезү аркасындагы туганлык (хатын-кызның сөт әтисе, сөт бабасы, сөт улы, сөт абыйсы, сөт энекәше һ.б.);
- никаһ сәбәпле туганлык (каената, ирнең улы, үги әти һ.б.).

[17] Мондый Хаҗ “мәбрур Хаҗ” дип атала.

(Аллаһ аннан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Бер Гомрә белән икенче Гомрә арасында кешенең гонаһлары гафу кылыныр, ә инде мәбрур Хажҗга килгәндә – мондый Хажҗның бүләге Җәннәттер”.*** Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ башка бер хәдисендә: ***“Кем Аллаһ ризалыгы өчен ихластан Хаҗ кыла һәм [шул Хаҗында үзенең телен] начар сүзләрдән, [үзенең калган әгъзаларын] гөнаһлардан саклый икән – [туган җирлегенә] әнисеннән әле генә туган бала кебек әйләнеп кайтыр”*** – дип әйткән.

Шушы биш баганага кермәсәләр дә, Ислам диненең башка төр нигезләре дә бар. Шулардан булып изге гамәлләргә өндәү һәм начар гамәлләрдән тыю тора. Аллаһ Тәгалә Көрьәндә әйтә:

**“Ий Мөхәммәд өммәте, дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, Аллаһка хак ышану белән ышандыгыз, кешеләрне хәерле эшләргә, изге гамәлләргә өнди белү белән өндәдегез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыя белеп тыйдыгыз”.** (“Әлү-Гыймран” сүрәсе, 110-нчы аять). Әүвәлге мөселман галимнәре әйтә иделәр: кем мөселман өммәтендә иң яхшылар рәтендә булуны тели, шул әлеге шартны үтәсен – изге гамәлләргә өндәүче һәм начар гамәлләрдән тыючы булсын.

Шулай ук, тагын бер мөһим нигез булып – Аллаһ юлында тырышлык күрсәтү тора. Шуның аша мөселманнарның абруе арта, Аллаһ дине күтәрелә һәм тарала, дошманнардан мөселманнарның ватаны сакланыла. Имам Әл-Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыкларында Ибн Гомәрдән (Аллаһ алардан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Миңа кешеләр белән, алар “Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк һәм Мөхәммәд Аллаһның расүле” – дип шәһәдәт китереп, биш вакыт намаз укып, зәкәт бирә башлаганчыга хәтле көрәш алып барырга әмер ителде, әгәр дә алар боларны үтәсәләр, миннән үзләренең җаннарын һәм малларын саклаган булырлар, ә ахыр хисаплары Аллаһ каршында булыр”.*** Шулай ук, имам Әхмәднең “Әл-Мүснәд” һәм имам әт-Тирмизинең “Җәмигъ” хәдисләр җыентыкларында сахих юл белән пәйгамбәребездән ﷺ риваять кылына, ул: ***“Бу эшнең башы – Ислам, аның терәге – намаз, ә өркәче – Аллаһ юлында тырышлык күрсәтү”*** - дигән.

Әбү Бәкер Әс-Сиддыйкъ (Аллаһ аннан разый булсын), хәлифә булып мөселманнар аңа бәйгать биргәч, шундый сүзләр әйткән: “*Әгәр дә халыклар Аллаһ Тәгалә юлында тырышлык күрсәтүне калдырсалар, аларга Аллаһ кимсетү һәм хурлык җибәрер*” – дигән. Аллаһ юлында тырышлык күрсәтү аша кешелеккә хаклык ирешә, батыл юкка чыга, Аллаһның шәригате күтәрелә, мөселманнар үзләре һәм аларның ватаны дошманнардан саклана.

Ислам дине – ул фитрый дин, ягъни Аллаһ Тәгалә тарафыннан кешенең табигый халәтенә салынган дин. Шулай ук, барча пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр өндәгән дин,

һәрбер пәйгамбәр үзенең кавемен мөселман булырга чакырган. Аллаһ Тәгалә Коръәндә пәйгамбәрләрнең атасы – Ибраһим пәйгамбәр ﷺ турында болай ди: **“Ибраһим тоткан ислам диненнән һичкем баш тартмас, мәгәр үз-үзенә ахмаклык кылган җәһил кеше генә баш тартыр. Шиксез, Ибраһимны Үзебез дөньяда имамлыкка һәм пәйгамбәрлеккә сайладык, һәм ул ахирәттә изгеләр белән җәннәттә булыр. Ибраһимга Раббысы әйтте: “Аллаһка итагать итеп чын мөселман бул!” Ибраһим: “Бөтен галәмнәрне тәрбияләүче Аллаһка итагать итеп чын мөселман булдым”, – диде. Ибраһим улларына васыять әйтте һәм әмер бирде: “Ий улларым, шиксез, Аллаһ сезгә ислам динен ирекле итте. Дөрес һәм ныклап Аллаһ динен тотыгыз! Мөселман булып яшәп, мөселман булган хәлдә генә вафат булыгыз!” Ягькуб та улларына шул ук сүзләрне әйтте”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 130-132 нче аятьләр).

Шушы бөек Ислам дине белән Аллаһ Тәгалә Үзенең ахыргы пәйгамбәрен һәм рәсүлен – Мөхәммәдне ﷺ җибәрде. Ә инде кайсыбер халыклар Ислам диненнән баш тартып, үзләренең нәфес теләкләренә ияреп, диннәрен үзгәртеп, адашу һәм белемсезлек юлын сайладылар. Алар арасыннан кайберләре Мөхәммәдне ﷺ Аллаһның ахыргы пәйгамбәре икәнлеген белә иделәр, Аллаһ Тәгалә моның турында Коръәндә җиткерә: **“Без Изге Китаплар биргән халыклар Мөхәммәдне үз балаларын таныган кебек таныйлар”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 146-нчы аять).

Шуңа күрә пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ Мәдинә шәһәрендә төпләнгәч, үзенең заманындагы төрле ил патшаларына, аларны Аллаһ диненә, көферлек караңгылыгыннан Ислам яктылыгына чакырып, хатлар җибәргән. Рибги ибн Гәмир исемле сахәбә (Аллаһ аннан разый булсын) фарсылар башлыгы Рустум янына килгәч, аңардан “*Сезнең чакыруыгыз нидән гыйбарәт?”*- дип сораганнар, һәм әлеге сахәбә “*Без, Аллаһ Тәгалә Үзе теләгән кешеләрне, мәхлукләргә гыйбадәт кылудан Бер Аллаһка гыйбадәт кылуга, тормышларындагы тарлыктан бу дөнья һәм ахирәт иркенлегенә, диннәрнең гаделсезлегеннән Ислам диненең гаделлегенә чыгару өчен җибәрелдек*”- дип җавап кайтарган.

Әлеге ахыргы дин – Ислам дине – барлык әйберне тәртипкә китерү һәм кешеләрне дөрес юлга юнәлтү өчен килде, ягъни кешеләр Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылып, Аның пәйгамбәр һәм рәсүлләрен танып, аларның барысына да иман китереп, башка кешеләрне Аллаһка һәм Аңа буйсынуга чакыру өчен иңдерелде. Башка халыкларга килсәк, алар Аллаһның пәйгамбәрләренә карата ике хаталы тарафка бүленделәр: бер тараф вәкилләре пәйгамбәрләргә карата салкынлык күрсәттеләр, аларны танымадылар һәм буйсынмадылар, хәтта кайсыберләренең гомерләренә һөҗүм иттеләр, пәйгамбәрләргә хас булмаган ялган сыйфатлар белән сыйфатладылар; ә икенче тараф вәкилләре капма-каршы якка чыктылар – пәйгамбәрләрне чиктән тыш олыладылар,

аларга Аллаһка гына хас булган сыйфатлар бирделәр, Аллаһ Тәгаләне зурлаган кебек зурладылар.

Һәм Ислам дине хакны – хак итеп, батылны – батыл итеп күрсәтте, башка диннәр арасында артыклык ягына да, кимчелек ягына да авышмыйча, алтын урталык һәм гаделлек дине булды. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Ий Мөхәммәд өммәте, сезне гаделлек, урталык тарафдарлары итеп кылдык, бу эшегез белән бөтен дөнья кешеләренә шаһит булуыгыз өчен, һәм Мөхәммәд тә сезнең хаклыкта булуыгызга шаһит булсын өчен”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 143-нче аять).

Шулай ук Аллаһ Тәгалә, Китап әһелләрен артыклык күрсәтүдән кисәтеп һәм тыеп, Коръәндә мөрәҗәгать итте: **“Ий Китап әһелләре! Динегездә артыклык кылмагыз, Аллаһ хакында ялганны сөйләмәгез, мәгәр аңа әйтергә тиешле хак сүзләрне генә әйтегез!”.** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 171-нче аять).

Шулай ук, пәйгамбәребез дә ﷺ Ибн Гәббәс (Аллаһ алардан разый булсын) исемле сахәбәдән тапшырыла торган үзенең бер хәдисендә: ***“Диндә артыклык белән шөгыльләнмәгез, сезгә хәтле булган кавемнәрне диннәрендә артыклык күрсәтү һәлак итте”*** – дип әйткән.

Ислам диненең кешеләр өчен күркәм һәм мөһим булган башка күп төрле исәпсез-хисапсыз сыйфатлары бар. Ничек инде шулай булмасын?! Ул бит – һәрнәрсәне белүче, тулы хикмәт һәм төпле дәлилләр иясе булган Аллаһ дине! Аллаһ Тәгалә Үзенең тәкъдир кылуында, хөкем итүендә һәм шәригатендә, карар кылына торган һәрбер эшендә Белүче һәм Хикмәт иясе! Шуңа күрә Аллаһның рәсүле пәйгамбәребез Мөхәммәд тә ﷺ нинди генә хәерлелек булмасын, барысына да чакырган һәм үзенең өммәтен шуңа юнәлткән, нинди генә начарлык булмасын, барысыннан да кисәтеп калдырган. Имам Мөслимнең “Сахих” хәдисләр җыентыгында Гәбдуллаһ ибн Гәмр ибн Гас (Аллаһ алардан разый булсын) исемле сахәбәдән риваять кылына, пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйткән: ***“Өммәтләргә нинди генә пәйгамбәрләр килмәсен – Аллаһ һәрберсенә дә аларга билгеле булган хәерлеккә өндәргә һәм һәрбер начарлыктан кисәтергә боерган”.*** Шулай ук хәфиз әл-Хараитый яхшы юл белән пәйгамбәребезнең ﷺ: ***“Мин, бары тик, күркәм әхлакне камилләштереп бетерү өчен генә җибәрелдем”*** – дигән сүзләрен китерә.

Йомгаклап әйткәндә, без бүгенге заманда төрле дин халыкларының күпләп Ислам динен кабул итүләрен күрәбез, бу башка диннәрнең һәм төрле фәлсәфәләрнең кешеләрнең күңелләренә тынычлык, иркенлек, тормышларына бәхет китерә алмаганлыгына өстәмә бер дәлил булып тора. Шуңа күрә, мөселманнарга гомумән һәм дингә өндәүчеләргә аеруча, шул халыкларны Аллаһ диненә чакыруда дәртле тырышлык куярга кирәклеген күрсәтә. Әлбәттә, иң беренче чиратта, үзебезнең тормышыбызда Ислам динен тиешенчә тотып, гыйлемнәребезне арттырып, шул

гыйлемгә нигезләнгән хәлдә гамәл-гыйбадәтләребезне кылып, башкаларга үрнәк булырга тиешбез! Кешелек җәмгыяте аларны көферлек, ширек караңгылыгыннан Ислам дине яктылыгына чыгаручыларга бик тә мохтаҗ! Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Ислам динендә, Коръән юлында файдалы эшләрне, изге гамәлләрне кылган хәлдә Аллаһка иман китерергә һәм ислам динен кабул итәргә кешеләрне чакыручы мөселманның сүзеннән дә күркәмлерәк, файдалырак сүз булырмы, һәм ул һәркайда әйтәдер: мин мөселман, бу эшләрне эшләргә мин бурычлымын, дип. Ягъни бу эш һәр мөселманның бурычыдыр”.** (“Фүссыләт” сүрәсе, 33-нче аять).

Аллаһ Тәгалә безләрне хәерлеккә өндәүчеләрдән, диннәрен, гыйлемгә нигезләнеп, дөрес аңлаучылардан һәм дингә чакыручылардан кылса иде! Бер Аллаһ кына моңа ярдәмче һәм куәте җитүче! Һәм Мөхәммәд пәйгамбәргә, аның гаилә әһелләренә, сахәбәләренә Аллаһның мактавы һәм сәламе булсын!